РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ул. Нагорная, 99а, с.Утяшки,
Зеленодольский район, 422514

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Нагорная ур., 99а, Өтәшкә ав ,
Зеленодольск р. 422514

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 27 июле № 17

«Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 10 номерлы карары (2021 елның 29 апрелендәге 17 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Өтәшкә авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләүне уздыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында»

«Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында» 15.06.2002 ел, № 1081 РФ Хөкүмәте Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ**:

1. Өтәшкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 31 мартындагы 10 номерлы карары (2021 елның 29 апрелендәге 17 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган (алга таба-тәртип) салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 3 пунктында « муниципаль программаларның структур элементлары турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Тәртипнең 12 пунктындагы икенче абзацында "муниципаль программаларның структур элементларын үстерү" төшереп калдырырга;

1.3. тәртипнең 12 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны һәм ташламаларны куллану өчен потенциаль хокукка ия түләүчеләр саны белән 5 еллык чорда күрсәтелгән ташламаларга түләүчеләрнең ихтыяҗы зур.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-

телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а (мәдәният йорты бинасы).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

**Өтәшкә авыл жирлеге башлыгы** **А.А. Клопов**

ИСПОЛКОМ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИНН 1648017990
ОГРН 1061673002973